


**Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдинов** 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Урта мәктәпне бетергәч, 1965-1961 нче елларда Казан дәүләт унивеситетында укыган. 1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. 1963-2007 нче елларда берөзлексез Мулла Иле мәктәбендә хезмәт иткән: авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, немец теле, гарәп теле, дин тарихы предметларын укыткан. 1968-1970 нче елларда – завуч, 1971-2000 нче елларда мәктәп директоры булган. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнгән. Республика матбугатында педагогик хезмәтләре, әдәби әсәрләре әле дә басылып тора. Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 нче елдан алып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифаларын башкара. 2017 нче елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә. 2018 нче елның 10 нчы февралендә вафат.

Сәйфетдинов Рөстәм Равил улы, Үзән шәһәре 16 нчы урта гомумбелем бирү мәктәбе диреторы

***Ялган шөһрәт, даннар белән түгел,***
***Эшең белән калдыр эзеңне.***
***Эзләп тапсын кеше мәхәббәте***
***Тормыш эчләреннән үзеңне.***

"Ялган шөһрәт белән түгел" исемле шигырьдән алынган бу юллар Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдиновның үзенә бик туры килеп тора. Мулла Иле урта мәктәбендә кырык биш ел буе берөзлексез тырышып, чын күңел биреп хезмәт иткән ул. Иң беренче чиратта, Равил Сәйфетдинов – коеп куйган укытучы. Йомшак күңелле, чын мәгънәсендә демократ, барлык кешеләрне дә эчкерсез ярата белә торган һәм үзе дә халык тарафыннан бик тә үз ителүче үзенә генә бертөрле булган зыялы шәхес иде ул.



*Утырганнар уңда әтисе **Гарәфетдин**, сулда Җамал (әтисенең абыйсы), уң якта әнисе **Бибинур баскан***



*Уң якта әтисе **Гарәфетдин** утырган*

Аның әтисе Гарәфетдин ике бертуганы Хәйретдин, Җамалетдин белән сугышта һәлак булганнар. Өч баласын җуйган Фатыйма ананың елый-елый ике күзе сукырайган.



*Сулда әбисе Фатыйма, уртада Җамал (җәмәгате белән)*



Ә әнисе Бибинур көн-төн колхозда эшләгән. Ләкин шундый шартларда да ул тәрбияле бала булып үскән.



*Әнисе колхоз эшендә вакытта*

*Әнисе Бибинур һәм әбисе Фатыйма янәшәсендә*



*Мәктәп еллары*



*Университет студенты*

Исәпсез-хисапсыз хуҗалык эшләренә кереп батса да, бертуктаусыз белемен баету белән мәшгуль булган. Авыл мәктәбен бетергәннән соң, 1956 нчы елда, җиде фәннән имтихан биреп, җидегә берле конкурста җиңеп, Казан университетының татар теле

һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән. Аның студентлык еллары Хрущёв җепшеклеге дип аталып йөртелүче хөрлек елларына туры килә.

Тәлгать Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Индус Таһиров, Фәрит Йосыпов, Хатыйп Миңнегулов, Нурмөхәммәт Хисамов, Рөстәм Кутуев кебек әдипләр белән бергә укый ул.



*Сабакташлар белән*



*Студент вакытта спектакль*



*Далада стенгазета чыгарганда*

Җәй айларында алар Казахстанда чирәм җирләрдә эшләгәннәр.

Равил Сәйфетдиновның 1958 нче елда басылып чыккан “Далада туган хисләр” дигән шигырьләр циклы бар. Аңарга сүз башын бик тә җылы итеп үзе дә җәй буе Казахстанда командировкада булган шагыйрь Мәхмүт Хөсәен язган. Үзенең “Далада туган хисләр” повестенда ул Равил Сәйфетдиновны шагыйрь-студент Сәйфи образында сурәтләгән. Тырыш хезмәте өчен Равил Сәйфетдинов биредә “Чирәм җирләрне үзләштергәне өчен” дигән медальбелән бүләкләнгән.



УДОСТОВЕРЕНИЕ

В соответствии с Указом Президиума Верховного Совета СССР от 20 октября 1956 года

Саифутдинов Равиль Гарафович

от имени Президиума Верховного Совета СССР награжден медалью

„ЗА ОСВОЕНИЕ ЦЕЛИННЫХ ЗЕМЕЛЬ“

От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль вручена

1. окт 1958 г.

А № 533972

Равил Сәйфетдинов педагогик практиканы Казанның 89 нчы татар мәктәбендә үтә. РСФСР ның атказанган укытучысы Фатыйма Җәләлиева – әлеге мәктәпкә Мулла Иле мәктәбеннән күчеп килгән татар теле мөгаллиме – аңа укыту серләрен төшендерә һәм ул үткәргән дәресләргә югары бәя куеп фатихасын бирә. Университетта диплом эше итеп ул иң авыр темаларның берсен сайлап ала: ”Карчыга” журналы – ХХ йөз башы матбугатының көзгесе”. Аңарга гарәп графикасында басылган “Карчыга” журналының бөтен саннарын җентекләп тикшерергә туры килә. Ул, бөтен күңелен куеп, архивта утыра. Милләтебезнең билгесез тарихы тынгы бирми аңа.



*Диплом яклаганда*

Бер үк вакытта кышкы каникулларда обком путевкасы белән Норлат төбәге авылларында милләтебез тарихы турында кызыклы лекцияләр укып йөри.

Университетны уңышлы тәмамлаганнан соң, Равил Сәйфетдиновны укытучы итеп Самара өлкәсендәге Гали авылы урта мәктәбенә җибәрәләр. Татар дөньясында шундый авыл да булуына ул гаҗәпләргә кала: тау астына җәелеп утырган галәмәт зур авыл, ике меңләп йорты, алты меңләп кешесе бар.



*Гали авылында дәрес биргәндә*

Иң хикмәтлесе: авылда өч мәчет гөрләп эшләп тора, өч манарадан көн саен азан әйтелә. Ә бит бу дин инде күптән тыелган, мәчетләр юк ителгән заманда, төштә түгел – өндә. Авыл халкы аны бик тә яратып өлгерә, чөнки ул университетта, гарәп телен һәм графикасын бик яхшы үзләштергәнгә, Коръәнне, аңлап, тәҗвид белән укый белә. Үзе җитәкче булып эшли торган сыйныф кызларын мәчет юарга тоткарлыксыз җибәреп бара. Бу авылда халык татар телендә Казанга караганда да матур сөйләшә. Равил Сәйфетдинов бу авылда ике ел эшли. Мәктәптә, бөтен көчен куеп, татар, рус, немец (немец телен ул камил белгән) телләрен укыта. Шушы телләр буенча бик күп методик әдәбият туплый. Шул телләрне үзе берөзлексез

чагыштырып өйрәнә. Аның бу өйрәнүе гомер буена китә, хоббиена әйләнә. Ул Тукай, Такташ, Илдар Юзеевларны тәүлекләр буенча русча сөйли ала, Пушкин, Евтушенколарны яттан сөйләп кенә калмый, татарчага тәрҗемә итә, Гёте, Гейнеләрнең шигырьләрен дә яттан белә һәм немецчәдән татарчага тәрҗемә дә итә. Ул күп мәртәбәләр үзешчән нәфис сүз осталарының республика конкурсында катнаша һәм берничә мәртәбә бөтенсоюз лауреаты исемен дә яулый. Руссия мөфтиләр шурасы берничә ел рәттән мәүлид ае уңае белән “Мөхәммәт Мостафа сәллаллаһу галәйһи вә сәллам – һәр ике дөньяга рәхмәт йөзеннән җибәрелгән Пәйгамбәребез” дигән темага карата татар һәм рус телләрендә иҗат ителгән иң яхшы шигъри әсәрләргә бәйгеләр үткәрелде. Равил Сәйфетдинов, соңгыларында катнашып, 2009 нчы елгысында “Иман нуры” дигән шигыре белән беренче урынга чыга. 2011нче елда “Сәхабәләр килгән Болгарга” дигән шигыре кабат җиңүгә лаек булып, ул, Шураның рәисе мөфти шәйх Равил хәзрәт Гайнетдин чакыруы буенча, Мәскәүгә бара һәм 22 нче февральдә мәркәзебезнең Җәмигъ мәчетендә мәүлид аена багышлап үткәрелгән форумда – дин әһелләре һәм зыялылар җыенында катнаша. Мәчетнең конференц-залында Мөфти хәзрәт, аны котлап, аңа диплом һәм бүләкләр тапшыра, Татарстан халкына, шул җөмләдән Мулла Иле кешеләренә үзенең сәламнәрен юллый Мөфти. Шигыре шактый озын булса да, аны ул трибунадан залдагыларга тулысынча укып чыга, чөнки аңа зур хөрмәт күрсәтеп, шигырен яратып тыңлыйлар. Нәкъ менә Гали авылында Равил Сәйфетдинов укучылар йөрәгенә юл табарга өйрәнә. Укытучыга бик күпне белергә кирәк, һәм шуның иң



*Мулла Иле мәктәбендә дәрес биргәндә*


*Мәскәүдә Муфтиләр Шурасы рәисе мөфти шәйх Равил хәзрәт Гайнетдин бүләкләве*

кирәклесен тиешле методик алымнар аркылы укучыга җиткерә алу – иң әһәмиятлесе.

Ул һәр дәрескә иҗат итү ялкыны белән керә, үзенең максатына ирешә, шуннан үзенә биниһая шатлык, ләззәт ала. Үзенең гомерлек юлын табып, сиксәнгә чаклы шул юлдан бер дә тайпылмыйча бара ул. (Гали авылы белән Равил Сәйфетдинов гомеренең азагына кадәр элемтәдә яши.)

1963 нче елдан башлап Равил Сәйфетдиновнең бөтен гомере Мулла Илендә уза. 1968 нче елда аны директор урынбасары итеп куялар, ә 1971 нче елның беренче гыйнварыннан 2000 нче елның беренче сентябренә кадәр директор итеп эшләтәләр. Мәктәп җитәкчесе булса да, Равил Сәйфетдинов гомергә укытучы булып кала. Үзенең һәрбер дәресенә, зур багаж, керсез иман белән кереп, иң катлаулы темаларны да укучылар рәхәтләндереп үзләштерә торган итеп оештыра. Һәр дәрестә укучылар мавыгып эшлиләр. Ул кырыслыкны, җитдилекне ягымлы юмор белән бик оста аралаштыра белә. “Кысып укытырга кирәк, ләкин диктатор булып түгел, елмаеп укытырга кирәк, тик уенга җибәреп түгел,” – дип әйтә торган булган ул. Директор булса да, әдәбият-тел түгәрәкләрендә укучылар белән “җенләнә”. Хәтта өйдә дә алар язган хикәя, шигырьләрне укып, шулар дөньясында яши. Шул аңа чиксез зур рәхәтлек бирә. Аның Рәмилә Майорова дигән укучысының әсәрләрен Казанда китап итеп бастырып чыгардылар (“Өмет бар килер көннәремдә”, 2000ел, Казан). Ул эшләгән елларда Мулла Иле мәктәбендә дистәләрчә дистәләрчә шагыйрьләр һәм язучылар кунакта була. Директолыкны Равил Сәйфетдинов бик тә гадел башкара. Укытучыларның барысы да аны бик яраталар. Мондый хәл, әлбәттә, бик сирәк була. Бөтен коллектив рәхәт иҗат итү атмосферасында яши. Казанда татар мәктәпләре калмаганга, 1970-1990 нчы елларда республиканың бик күп семинарлары нәкъ менә Мулла Иле мәктәбендә үтә.



*Мулла Илендә язучыллар*

Равил Сәйфетдинов һәр семинарда ачык дәрес күрсәтә һәм доклад ясый. Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы җитәкчессе Хәбибуллина З.Н. мәктәпкә килгән саен: ”Бу мәктәп директорын нинди чемоданга салып үзебез белән алып китәргә икән? – дип әйтә торган булган. Әйе, Равил Сәйфетдинов директор булып эшләгән еллар мәктәпнең укучыларга бай, нәтиҗәле рәвештә гөрләп эшләгән еллары булган.



*Мулла Илендә галимәләр*

Равил Сәйфетдиновнең үз тәҗрибәсеннән алып язылган бик күп мәкаләләре “Мәгариф” журналында басылалар. Ул гомер буе матбугат белән бергә яши. Өенә ул дистәләгән газета, ким дигәндә алты-җиде журнал яздыра торган була. Гомере буе китап җыя. Аларның ул берсен дә югалтмыйча саклый. Китап сорап, хәтта күрше авыллардан әллә кемнәр килә торган була аңа. Сораган китапларын табып биргәч (картотека булмаса да, ул аларның һәрберсенең кайда торганын яхшы белгән), түбәсе күккә тия торган була. Ул гел шундый нәрсәләрдән тәм табып яши, акча исәбен гомер буе белми. Ә менә бик кадерле берәр китабын югалтсалар (андый очраклар байтак була), иң зур нәрсәсен югалткандай, шактый эче пошып йөри.

Мәктәптә Равил Сәйфетдинов бик зур хуҗалык эшләре башкара. Дөресрәге, булдырып булмаганны да булдыра. Монда аның беркатлылыгы да, дәүләт эшен үз эшеннән өстен куюы да ачык күренә. 1974 нче елда, җәйгә чыккач, балта осталары яллап, ике катлы иске агач мәктәпне сүттереп аттыра, урманнан бүрәнәләр ташытып, искесен һәм яңасын бергә кушып, бер катлы зур мәктәп төзеттерә. Ләкин мәктәп беренче сентябрьгә өлгерми. Укытуны төрле өйләрдә оештырга туры килә. Көлүчеләр дә күп була. Ләкин беренче гыйнварга яңа мәктәп өлгерә. Укучылар, укытучылар җылыга тиенәләр. Мәктәпкә су кергән, котельныйдан рәхәт җылы килә. Гомердә күрмәгәнне күрә укучылар. Кыюлар юләрлеге шулай була икән.

1986 нчы елда хәзерге типовой таш мәктәп бинасын булдыру өчен дә Равил Сәйфетдиновка бик күп чабарга туры килә.

Һәр кабинетны заманча итеп җиһазлауга ирешә, газ керттерә, мәктәп тирәсен гөлбакчага әйләндерә, теплица ясатып, кыш буе җәмәгатеннән (Сәйфетдинова Роза Сәлимовнадан) – теплицаның җитәкчесе булган биология укытучысыннан – яшелчәләр, чәчәкләр үстерттерә ул. Теплица гөрләп эшләгән елларда, ел әйләнәсендә укучыларның табыннары яшелчәләрдән өзелми. Иң гаҗәбе шунда: бөтен илдә кешеләр күп нәрсәне эштән чәлдерә торган бер заманда Равил Сәйфетдинов мәктәп хуҗалыгыннан бер шырпы кисәге дә алып кайтмый, киресенчә, кадагынмы, көрәгенме мәктәбенә өйдән үзе ташый.



*Яңа мәктәпне ачканда, 1986 нчы ел*

Равил Сәйфетдиновнең үзен-үзе аямыйча эшләве нәтиҗәсе буларак, Мулла Иле мәктәбе 1970-2000 нче елларда, күп кенә казанышларга лаек була. Татар теле һәм әдәбияты кабинеты республика күләмендәге конкурста беренче урынны ала, видеомагнитофон белән бүләкләнә (ул вакытта халык видеомагнитофонның нәрсә икәнен дә белми әле, бөтен авыл, мәктәпкә җыелып, шушы хикмәтле тартма эченнән чыга торган киноларны карарга йөри), мәктәп “Ел мәктәбе” исеменә лаек була. Татар теленнән, әдәбиятыннан бик күп еллар район олимпиадаларында беренчелекне Мулла Иле укучылары яулыйлар...

Равил Сәйфетдинов эшендә һәм тормышында гаҗәп тыйнак булып кала: куштанланып, зур дәүләт бүләкләре артыннан чапмый (ә авылның орден-медаль алучы кешеләренә кирәкле документларның барысын да ул тутыра торган була). Алай гына түгел, ул хәләл җефетен– мәктәпнең тәҗрибәле һәм нәтиҗәле эш күрсәтүче биология һәм химия укытучысын бүләкләнүгә тәкъдим итүдә дә бик тыйнаклык күрсәтә. Бервакытны өстән Роза Сәлимовнаны “РСФСРның атказанган укытучысы” исеменә тәкъдим итәләр.

Район мәгариф бүлеге характеристикалар тутырттыра. Әмма директор Равил Сәйфетдинов: ”Ул болай да атказанган!” дип, үзенең беркатлылыгы белән моны тормышка ашырмый кала.





Роза Сәлимовна үзе, чынлап та, исемнәрдән курка торган була.



*Теплицада*

Чөнки ул бер эшне дә кеше күрсен дип күргәзмә өчен эшләми. Мәктәптә теплица корылып беткәч, анда укучылары белән кыш көннәрендә чәчәкләр, яшелчәләр үстерә, семинарларны гына түгел, “гади” дәресләрне дә теплицада үткәрергә иренми ул. Теплицада ташбакалар, күбәләкләр кыш көннәрендә дә рәхәтләнеп яшиләр ул заманда. Мәктәп бакчасының гөлбакчага әйләнүендә дә Роза Сәлимовна хезмәтенең өлеше бик зур була.

Равил Сәйфетдиновнең хезмәте бәяләнмичә калмый. Аңа “Россиянең мәгариф отличнигы”, “Татарстанның атказанган укытучысы” исемнәре, “СССР Мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы”, “Хезмәт ветераны” медале бирелә.



*“Татарстанның атказанган укытучысы” исемен тапшырганда*

Табигать балалары буларак, Сәйфетдиновләр ачык һавадагы кыр эшләрен бик яраталар. Җәй саен болында гаилә белән чыклы иртәләрдә печән чабалар, челләләрдә дистәләгән чүмәләләр өяләр. Гомер буе хуҗалыкта сыер-сарык тоталар, тавык-каз асрыйлар, урманнан җиләк-җимеш җыялар.



Натураль хуҗалык белән шөгыльләнү иҗади һәм педагогик эшчәнлеккә ярдәм генә итә шикелле. “Зыялы булу өчен табигать кочагында ял итү генә җитми, ә хезмәт итү дә зарур”, – дип әйтә торган була Равил Сәйфетдинов. Колхозлар яшәгән чорда һәр хуҗалыкка бүленеп бирелгән кишер, суган, чөгендер участокларын ул (кешеләр әйткәнчә, “директор башы белән”) барлык кешеләр белән рәхәтләнеп эшкәртә. “Кеше белән бергә эшләүгә бернәрсә дә җитми, тигезлек җанны рәхәтләндерә“, – дип әйтә ул. Ә үзе барлык кешеләрдән дә күбрәк һәм тырышыбрак эшли.



*Җиләк җыйганда*

Равил Сәйфетдинов җәмәгать эшләрендә кайнап яши. Район Советы депутаты буларак, авылларга асфальт юл салдыруга үзеннән зур өлеш кертә. Агитаторлар коллективы җитәкчесе, пропагандист, авыл Советы рәисе урынбасары, Иптәшләр суды рәисе, комсомол секретаре, “Белем җәмгыяте” лекторы... Ул шушы эшләрнең барысын да чын күңелдән, бирелеп эшли. Шуның өстенә төннәрен кичке мәктәптә яшьләрне укыту-тәрбияләүгә күпме елларын багышлый.



*Археолог А.Бурһанов белән Өтәк шәһәрлегендә*

Равил Сәйфетдинов туган авылы Мулла Иле һәм районыбыз тарихын өйрәнүдә зур хезмәт куя. 1990 нчы елда авылның 750 еллык юбилее республика күләмендә нәкъ менә аның тырышлыгы нәтиҗәсендә зурлап билгеләп үтелә. Ул анда авыл тарихына багышланган зур доклад белән чыгыш ясый. Мәктәптә республика музейлары көнләшерлек “Авыл тарихы” музеен оештыра.

Равил Сәйфетдинов – шигырьләренә үз вакытында Хәсән Туфан югары бәя биргән үзенчәлекле шагыйрь. Мәктәп елларыннан алып гомеренең азагына кадәр ул иҗат белән шөгыльләнә. Аның “Ак төнбоек күлләрдә” дигән шигырьләр циклы Илдар Юзеевның сүз башы белән басылып чыга (1998). Халык шагыйре аның турында үзе “мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес” ләрнең берсе дип язган. 2000 нче елда Равил Сәйфетдиновнең “Кичке шәфәкъ”, 2010 нчы елда “Мулла Иле моңнары”, 2014 нче елда “Бәхет үзәне”, 2017 нче елда “Аксакал язмалары” исемле шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр китаплары дөнья күрә. Гаҗәп игътибарлы һәм хәтерле кеше буларак, ул авылдагы һәм якын-тирәдәге хикәятләрне, мәзәк хәлләрне хәтерендә сеңдереп бара һәм аларны, әдәби яктан эшкәртеп, вакытлы матбугатта бастырып чыгара торган була. Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай һәм “татар тарихы атасы” Шиһабетдин Мәрҗаниләрнең Мулла Илендә булулары, шушы авылда туып үскән дин һәм җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь Баһаветин Вәисов иҗаты, аның улы Гайнан Вәисовның Ясная Полянада Лев Толстой янында кунакта булуы, Мулла Иле авылыннан чыккан татар тарихчысы Хәйретдин Гыймади эшчәнлеге турында яңа эчтәлектәге материаллардан торган саллы мәкаләләре укучыларда зур кызыксыну тудыра.



*Тукай – Мулла Илендә.*

Гомеренең соңгы көненә кадәр Равил хәзрәт Сәйфетдинов Мулла Иленең имам-хатыйбы вазифаларын башкара. Мәхәлләгә вәгазь тыңларга, гает бәйрәмнәренә халык элеккегедән күбрәк һәм тәртиплерәк йөри башлаган икән – бу аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Һәрбер дини чарага нинди олы иман, нинди зур тырышлык белән әзерләнә иде ул! Әйе, Халыкның рухи-әхлакый киләчәге өчен нык борчылып яши ул. Шунлыктан, мәчеткә йөри башлауга ук, ул мәчет каршындагы мәктәптә балаларга дини сабак укыта башлый (хәер, әлеге изге эшне ул факультатив дәресләрдә мәктәптә дә алып бара торган була). Кечкенә генә балалар, ашыга-ашыга, мәчеткә дин дәресләрен алырга йөриләр, чөнки биредә аларга ап-ак йомры сакаллы, йомшак күңелле бабайлары колак ишетмәгән нәрсәләр турында сөйләп, аларны физкультура дәресләре кебек үк күңелле булган намаз рәтләренә өйрәтә.




*Мулла Иле мәчетен ачу*

Сиксән яшен тутырып килүгә карамастан, кешеләргә күбрәк яхшылыклар эшләп калдыру өчен, киләчәккә яңа планнар корып яшәде Равил хәзрәт. “Мәңгелеккә килдем дип казган, иртәгә үләм дип, гыйбадәт кыл”, – дип әйтә торган булган ул, чыны-шаяртуы белән бергә.



*Габделхәмит хәзрәт Мулла Иле мәчетендә*